**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

2021 елның 20 декабреннән №49

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1 нче статья

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге бюджетының (алга таба - Турай авыл җирлеге бюджеты) төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Турай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 1666,963 мең сум тәшкил итә;

2) Турай авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1666,963 мең сум тәшкил итә.

3) Турай авыл җирлегенең бюджет дефициты - 0 мең сум.

2. 2023 һәм 2024 еллар план чорына Турай авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Турай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2022 елга 1680,565 мең сум һәм 2023 елга 1725,651 мең сум күләмендә;

2) Турай авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2022 елга 1680,565 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 39,33075 мең сум күләмендә;

- 2023 елга 1725,651 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 880,724мең сум күләмендә.

3. 2022 елга һәм 2023 еллар план чорына Турай авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 нче статья

1. 2023 елның 1 гыйнварына Турай авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча - 0 мең сум.

2. 2024 елның 1 гыйнварына Турай авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

3. 2025 елның 1 гыйнварына Турай авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

3 нче статья

Турай авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2022 елга һәм 2023, 2024 елларның план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 нче статья

1. Турай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Турай авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 нче статья

Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан Турай авыл җирлеге бюджетына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен расларга:

- 2022 елга 542,470 мең сум күләмендә;
- 2023 елга 547,130 мең сум күләмендә;
- 2024 елга 584,780мең сум күләмендә.

6 нчы статья

Турай авыл җирлеге бюджетында Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирә торган субвенцияләрне расларга:

- 2022 елга 103,793 мең сум күләмендә;
- 2023 елга 107,335 мең сум күләмендә;
- 2024 елга 111,171 мең сум күләмендә.

7 нче статья

1. Турай авыл җирлеге бюджетыннан тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район бюджетына күчерелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- 2022 елга 6,200 мең сум күләмендә;
- 2023 елга 6,200 мең сум күләмендә;
- 2024 елга 6,200 мең сум күләмендә.

2. Менделеевск муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны еллык ассигнованиеләрдән ай саен тигез өлешләр белән күчерүне тәэмин итәргә.

8 нчы статья

1. Турай авыл җирлеге башкарма комитеты 2022 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 нчы статья

Турай авыл җирлеге бюджетының файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артып китмәгән күләмдә, әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2021елда түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә тотылган муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан 2022 елда, тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

10 нче статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Турай авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

11 нче статья

Әлеге карарны Турай авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

13 нче статья

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге
Советы Рәисе А.М. Рәхимова